# КАРАР

**30 ноябрь, 2023 ел** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлеге Яңа Комар авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 30 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Оштырма-Юмья авыл җирлеге Яңа Комар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Яңа Комар авылының Урман урамы, Яшьләр урамында юлларны төзү, ремонтлау, карап тоту, вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, суүткәргеч торбалар урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү, Яңа Комар авылында янгын гидрантларын, янгын сүндерү рукавлары, стволлары, күчергечләре, колонкалары, мотопомпалары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- Яңа Комар авылында суүткәргеч системасын, су суырту манарасын, скважиналарны һәм башка инженерлык челтәрләрен ремонтлау, карап тоту һәм төзекләндерү, кул белән һәм экскаватор белән туфрак эшкәртү, торба үткәргеч салу, ремонтлау, су суырту манарасы өчен бетон боҗралар, капкачлар һәм люклар, насос сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, экскаватор һәм манипулятор хезмәтләре өчен түләү, эш өчен шартнамә буенча түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;»
- урам яктырту җайланмасы, урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Яңа Комар авылының урам юл челтәрен карап тоту, кышын юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу, төзекләндерү; трактор һәм чапкыч

өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

2023 елның 30 ноябренә торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны – 127 кеше.

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 103 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 66 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 66 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Яңа Комар авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Оштырма Юмья авыл җирлеге Яңа Комар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Яңа Комар авылының Урман урамы, Яшьләр урамында юлларны төзү, ремонтлау, карап тоту, вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, суүткәргеч торбалар урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү, Яңа Комар авылында янгын гидрантларын, янгын сүндерү рукавлары, стволлары, күчергечләре, колонкалары, мотопомпалары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- Яңа Комар авылында суүткәргеч системасын, су суырту манарасын, скважиналарны һәм башка инженерлык челтәрләрен ремонтлау, карап тоту һәм төзекләндерү, кул белән һәм экскаватор белән туфрак эшкәртү, торба үткәргеч

салу, ремонтлау, су суырту манарасы өчен бетон божралар, капкачлар һәм люклар, насос сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, экскаватор һәм манипулятор хезмәтләре өчен түләү, эш өчен шартнамә буенча түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;»

- урам яктырту җайланмасы, урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү;

- Яңа Комар авылының урам юл челтәрен карап тоту, кышын юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу, төзекләндерү; трактор һәм чапкыч өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү;

территорияне төзекләндерү, яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Оштырма Юмья авыл җирлеге башлыгы: С.В. Тимофеев